РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕКИБЯКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ул. Ленина, д.31, офис 1**
**село Верхние Кибя-Кози,**
**422083**
**тел.(884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**Ленин урамы, 31 енче йорт,**
**1 енче офис, Югары Кибәхуҗа**
**авылы, 422083**
**тел. (884360) факс: 56-5-42**
E-mail: VKbk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318107 ОГРН 1061675010836 ИНН/КПП 1619004443/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИE** **КАРАР**

**№6** **«07» февраля 2023 ел**

Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 20 мартындагы 5 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру» турында карары белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Монополиягә каршы законнарны (№ АШ-06/15096 от 13.12.2022) бозу билгеләрен үз эченә алган гамәлләрне (гамәл кылмауны) туктату турында №П06-/2022 номерлы кисәтүне карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Профессиональ керемгә салым» махсус салым режимын билгеләү буенча эксперимент уздыру турында» 2018 елның 27 11 декабрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1.Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2017 елның 20 мартындагы 5 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру» турында карары белән расланган «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына аукцион үткәрү Тәртибенә (алга таба - Тәртип) үзгәрешләр кертергә:

1.1. Тәртипнең 4 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә: «4. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга шартнамә төзү хокукына сүәдәләрдә оештыручы-хокукый рәвешкә, милек рәвешенә, тору урынына бәйсез рәвештә теләсә кайсы юридик зат, индивидуаль эшкуар, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә төзүгә дәгъва кылучы һөнәри керемгә салым түләүче (үз-үзенә эшләүче) катнашырга мөмкин.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Югары Кибәхуҗа авыл
җирлеге башлыгы                                                                Ф.Р. Мәхмүтов